РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ БОЛЬШЕШИНАРСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422054, Республика Татарстан,
Сабинский район,с.Большой Шинар,
ул. Кооперативная,дом 36
тел. (84362) 41-2-11

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ ШЫҢАР АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422054, Татарстан Республикасы,
Саба районы,Олы Шыңар авылы,
Кооператив урамы, 36 йорт
тел. (84362) 41-2-11

e-mail: bshin.sab@tatar.ru

РЕШЕНИЕ
28.07.2023

КАРАР
№19

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 2021 елның 08 ноябрендә кабул ителгән 22нче номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге чикләрендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советы

КАРАР БИРӘ:

1.Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының “Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге чикләрендә муниципаль торак контроле турындагы нигезләмәне раслау хакында” 08.11.2021 елда 22нче номерлы карары белән расланган Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге чикләрендә муниципаль торак контроле турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

**1.1.** «энергетика нәтиҗәлелеге» сүзләреннән соң беренче абзацны «Россия Федерациясендә газ белән тәэмин итү турында законнар» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

**1.2.** 1.2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге 12 нче пунктчасы белән тулыландырырга:

«12) йорт эчендәге һәм (яки) фатир эч ендәге газ җиһазларын куркынычсыз эксплуатацияләүгә һәм техник хезмәт күрсәтүгә таләпләр, шулай ук күп фатирлы йортта гомуми милеккә караган вентиляция һәм төтен каналларын тотуга таләпләр.»;

**1.3.** 1.6 нчыпунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Муниципаль торак контроле объектлары булып санала :

1) контрольдә тотылган затларның эшчәнлеге, гамәлләре (гамәлсезлеге), алар кысаларында мәҗбүри таләпләр үтәлергә тиеш, шул исәптән әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктының 1- 12 пунктчаларында күрсәтелгән эшчәнлек алып баручы контрольдә тотылган затларга карата куелган гамәлләр (гамәлсезлеге);

2) контрольдә тотылган затларның эшчәнлеге нәтиҗәләре, шул исәптән продукция (товарлар), эш һәмхезмәтләр, аларга әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктының 1- 12 пунктчаларындакүрсәтелгәнмәҗбүриталәпләркуела;

3) муниципаль торак фондының торак биналары, муниципаль торак фондының торак биналары булган күп фатирлы йортлардагы гомуми милек һәм әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктындагы 1-12 пунктларында күрсәтелгән мәҗбүри таләпләр куела торган башка объектлар.»;

**1.4.** 1.7 нче пунктта өченче абзацны алырга;

**1.5.** 5 нче бүлекне алырга. Судка кадәрге шикаять.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында: http://saby.tatarstan.ru/shinar адресы буенча бастырып чыгарырга.

3. Карар рәсми бастырып чыгарган көннән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен тикшерүне үз өстемә алам.

Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы А.Г.Гарипов